# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Гаилә кодексының
56 һәм 57 статьяларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 15 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

2009 елның 13 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 56 статьяның 6 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Балаларның яшәү урынын билгеләү турындагы суд карары законлы көченә кергәнчегә кадәр чорга аларның яшәү урынын билгеләү Россия Федерациясе Гаилә кодексының 65 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.”;

2) 57 статьяның 4 өлешенә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Суд карары законлы көченә кергәнчегә кадәр чорга ата-ана хокукларын үтәү тәртибен билгеләү Россия Федерациясе Гаилә кодексының 66 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 24 сентябре
№ 61-ТРЗ